**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 20 февраль № 106

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турында» 2004 ел, 10 ноябрь, 480 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турында» 2004 ел, 10 ноябрь, 480 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 14 июнь; 265 нче; 2005 ел, 8 сентябрь, 442 нче; 2006 ел, 30 гыйнвар, 33 нче; 2007 ел, 29 гыйнвар, 22 нче; 2007 ел, 5 март, 70 нче; 2008 ел, 4 февраль, 61 нче; 2009 ел, 9 сентябрь, 628 нче; 2009 ел, 18 декабрь, 860 нчы; 2013 ел, 4 март, 144 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

22 нче пунктның алтынчы абзацында «гадәттән тыш хәлләрне бетерү эшләре җитәкчесе» сүзләрен «гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча җитәкче» сүзләренә алмаштырырга;

$24^1$ нче пунктта:

дүртенче абзацта «җирлекләре» сүзен «шәһәр җирлеге» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «керә торган» сүзләренә кадәр «яки бер авыл җирлеге территориясе» сүзләрен өстәргә;

27 нче пунктта тиешле килешләрдәге «гадәттән тыш хәлләрне бетерү эшләре җитәкчеләре» сүзләрен тиешле килешләрдәге «гадәттән тыш хәлләрне бетерү

буенча җитәкчеләр» сүзләренә алмаштырырга;

28 нче пунктта «гадәттән тыш хәлләрне бетерү эшләре җитәкчеләре» сүзләрен «гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча җитәкчеләр» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\106.doc